Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы

Дәүләт бюджет оешмасы
“К.Тинчурин ис. Татар дәүләт драма һәм комедия театры”

420015 ТР, Казан шәһәре, М.Горький ур., 13 йорт.
Тел./факс: 264-35-18
www.tinchurinteatr.ru
E-mail: karimkonkurs@mail.ru

Министерство культуры Республики Татарстан

Государственное бюджетное учреждение
«Татарский государственный театр драмы и комедии им. К.Тинчурина»

420015 РТ, г. Казань, ул. М.Горького, д.13.
Тел./факс: 264-35-18
www.tinchurinteatr.ru
E-mail: karimkonkurs@mail.ru

исх.02/550 от 27.08.2021г.

Татарстан Республикасының
мәгариф һәм фәннәр министры
И.Г.Хадиуллинга

Хөрмәтле Илсур Гәрәй улы!

1 сентябрь - 22 ноябрь көннәрендә, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында, Туган телләр һәм Халыклар бердәмлеге елы һәм татар театрына нигез салучыларның берсе – бөек драматург, актер, режиссер Кәрим Тинчуринның тууына 134 ел тулу уңаеннан, X Халыкара заман милли драматургия театр фестивале кысаларында, **V Бөтенроссия мәктәпләре фестивале үткәрелә.**

Әлеге фестиваль беренче тапкыр Татарстан Республикасының барлык район мәктәпләре катнашында 2012 нче елда үткәрелде. Хәзер исә Кәрим Тинчуринның иҗатына багышланган фестиваль Россия һәм Татарстан Республикасы мәктәпләре арасында уза. Фестиваль татар театрлары һәм мәктәпләре арасындагы бәйләнешне ныгыта, укучыларны тәрбияләүдә уңай йогынты ясый.

Хөрмәтле Илсур Гәрәй улы! Сездән Татарстан Республикасы мәктәпләрендә Бөтенроссия фестивален үткәрүне рөхсәт итүегезне һәм фестивальнең нигезләмәсен Татарстан Республикасының барлык шәһәр һәм район мәктәпләренә җибәрүегезне сорыйбыз.

Зур хөрмәт белән,
директор

Ф.Н.Мөсәгыйтов
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

V Бөтенроссия мәктәпләре фестивале

Туган телләр һәм Халыклар бердәмлеге елы һәм татар театрына нигез салучыларның берсе – бөек драматург, актер, режиссер Кәрим Тинчуринның тууына 134 ел тулу уңаеннан үткәрелә торган Бөтенроссия мәктәпләре фестиваленең нигезләмләсе

(кыскартып - фестиваль).

Фестиваль Кәрим Тинчурин исемендәге X Халыкара заман милли драматургия театр фестивале кысаларында үткәрелә.

Әлеге фестиваль беренче тапкыр Татарстан Республикасының барлык район мәктәпләре катнашында 2012 нче елда үткәрелде. Хәзер исә Кәрим Тинчуринның иҗатына багышланган фестиваль Россия һәм Татарстан Республикасы мәктәпләре арасында уза. Бу исә үткәрү татар театрлары һәм мәктәпләре арасындагы бәйләнешне ныгыта, укучыларны тәрбияләүдә уңай йогынты ясый.

2. **Фестивальнең максат һәм бурычлары:**

- Кәрим Тинчуринның тормышын һәм иҗатын тирәнтен өйрәнү;

— Кәрим Тинчурин иҗатына таянып, гомумбелем бирү мәктәпләрендә укучыларда һәм яшүсмерләрдә эстетик, рухи тәрбия үсешен активлаштыру;

— балаларны милли театр сәнгатенә, драматургия һәм әдәбиятка, музыкага һәм хореографиягә тарту;

— сәнгатьнең кайбер төрләрендә талантлы яшьләрне ачу, аларга булышлык итү;

— татар халкының мәңгелек традицияләренә, ана теленә мәхәббәт тәрбияләү;

— классик әдәбият аша дөньяга карашны киңәйтү;

3. **Гамәлгә куючылар һәм оештыручылар:**

-Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

-Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы;

-ДБО “Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры”

- Татарстан Республикасы Язучылар берлеге;

- Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге.

4.Фестивальне оештыру һәм үткәрү тәртибе:

Фестивальгә җибәрелгән иҗади эшләрне Татарстан Республикасының танылган сәнгать әһелләреннән, фән һәм җәмәгать эшлеклеләреннән торган жюри бәяли.

Фестивальдә катнашу бушлай. Конкурска җибәрелгән эшләр кире кайтарылмый, әмма автор рөхсәте белән республика мәгълүмат чараларында кулланылырга мөмкин.

Фестивальдә катнашучылар:

Фестивальдә Россиянең гомумбелем мәктәпләренең 5-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала.

Фестивальнең тематикасы:

Фестивальдә Кәрим Тинчурин пьесаларыннан һәм милли классик драматургиянең асыл үрнәкләреннән сәнгать эшләре күрсәтү карала.

1.Спектакльдән өзек (вокал яки бию булуы хуплана (8-10 мин.));

2. Спектакльдән монолог (3-4 мин.);

3.Спектакльдән җыр (дуэт);

4. Рәсем-эскиз (укыган пьеса, караган спектакль буенча)

Фестивальне үткәрү тәртибе:

Фестиваль 2021 нче елның 1 нче сентябреннән 22 нче ноябренә кадәр 3 этапта үткәрелә:

I этап — муниципаль җирлекләрдә. 2021 нче елның 1 нче сентябреннән 20 нче октябренә кадәр үткәрелә.

II этап – Республика күләмендә. 2021 нче елның 1 нче ноябреннән 20 нче ноябренә кадәр үткәрелә.

III этап – 2021 нче елның 22 нче ноябрендә үткәрелә.

Номинацияләр:

Фестивальдә түбәндәге номинацияләр һәм призлар булдырыла:

“Спектакльдән җыр” номинациясе:

-музыкаль әсәрнең сәнгати башкарылышы;

-интонациянең чисталыгы һәм яңгыраш сыйфаты;

-тембр матурлыгы һәм тавыш чисталыгы.

“Спектакльдән өзек” номинациясе:
-образны ачу;

-сәхнә культурасы, декорация, костюм;

-өзекнең катлаулылыгы.

“Спектакльдән монолог” номинациясе:
-өзекнең башкару мөмкинлекләренә һәм яшь категориясенә туры килүе;

-башкару осталыгы;

-сәнгатьле башкаруның төрле чараларын куллану (костюм яки декорация элементлары, музыкаль бизәлеш).

“Рәсем-эскиз” номинациясе:
-күзаллауның сәнгати дәрәҗәсе;

-эчтәлек тирәнлеге, грамоталылыгы;

-эшне башкаруга иҗади якын килү, оригинальлек.

Барлык катнашырга теләүчеләр ДБО “Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры“ адресына күрсәтелгән форма буенча гариза җибәрә**.**
- Гаризалар почта бүлекчәсе яки электрон элемтә аша (театрга китереп тә бирергә дә мөмкин) 2021 нче елның 20 нче октябреннән 10 нче ноябренә кадәр кабул ителә.

- Шулай ук, кушымта 1 формасында тутырылган гаризалар, спектакльдән җыр, спектакльдән өзек, спектакльдән монолог (MP4 форматындагы видеофайл, горизонталь ориентациядә), А-3 форматындагы рәсем-эскиз эшләрен 2021 нче елның 20 нче октябреннән 10 нчы ноябренә кадәр җибәрү сорала.

ДБО “Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры”ның электрон почтасына (tinchurinmuseum@mail.ru) җибәрә ала (адресы: Казан шәһәре, Горький урамы, 13 нче йорт). Тел. 236-66-89; 8-927-031-36-82;

Музей җитәкчесе - Чабатова Розалия Вәлиәхмәт кызына (барлык сораулар буенча шалтыратырга мөмкин).

Шулай ук, фестиваль эшләрен театрга 9.00 - 18.00 сәгатьләрдә китерергә дә мөмкин.

Укучылар тарафыннан җибәрелгән иҗат эшләре 1-15 ноябрьгә хәтле мәртәбәле жюри тарафыннан карала:

5 ноябрь - Спектакльдән өзек;

8 ноябрь - Спектакльдән монолог;

9 ноябрь - Спектакльдән җыр;

10 ноябрь - Рәсем-эскиз.

Финалга чыккан катнашучыларга мәгълүмат хат аша 10 көн алдан җибәрелә.

Фестиваль турындагы мәгълүмат белән Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры социаль челтәрләрендә танышырга була.

Бүләкләү:

Оештыру комитеты түбәндәге призларны булдыра:

— Фестивальнең истәлекле, кыйммәтле билгесе, диплом һәм башка истәлекле бүләкләр;

— Фестивальдә катнашкан барлык укучыга һәм аның җитәкчесенә шәһадәтнамә бирелә. Барлык катнашучыларга шәһадәтнамәләр гала-концерт узганнан соң электрон формада 15 көн эчендә җибәрелә.

Кушымта 1

Туган телләр һәм Халыклар бердәмлеге елы һәм татар театрына нигез салучыларның берсе – бөек драматург, актер, режиссер Кәрим Тинчуринның тууына 134 ел тулу уңаеннан үткәрелә торган V Бөтенроссия мәктәпләре фестивалендә катнашу өчен

гариза үрнәге

	Катнашучылар исемлеге				
Белем бирү оешмасының исеме	Әсәрнең тулы исеме, авторы	Ф.И.О.	Уйнаган роле	Туган вакыты, тулы яше, сыйныфы	Җитәкченең Ф.И.О., телефоны, электрон адресы

Сәхнәләштерелгән өзеккә бәяләмә (аннотация) җибәрүегезне сорыйбыз.